№ 52 (1179), 22 декабрь 2012 ел

яисә хайванның башын алып, аны үтәли тишеп яки шуңа охшаш ничектер итеп ясалган икән, бу очракта әлеге сурәт тыелган булудан туктый. Бу скульптурага кагыла;

- әгәр бу сурәтнең шәүләсе булса. Әмма әгәр стенага беркетелгән сурәтнең шәүләсе булмаса, ул тыелган булмый.

Бу өч шартның һәммәсе кыз балалар уйный торган курчакларга хас булса да, алар барыбер рөхсәт ителәләр. Ни өчен? Чөнки бу курчаклар кызларны балачактан ук бала карарга һәм тәрбияләргә өйрәтү максаты белән җитештереләләр.

Ник фотоаппарат ярдәмендә төшерелгән гәүдәләр сурәтләнгән фоторәсемнәр турында бәхәс алып барырга: аларның шәүләләре яки күләмнәре бармы әллә?

Бер вакыйга турында искә төшереп үтү бик мөһим. Әбү Бәкер хәлифә идарә иткән чорда Византия патшасы Ираклий (Һәркәл) яшәгән, аны исламны кабул итәргә чакырганнар. Менә сәхабә Һишам ибн Әснең аңа таба юнәлгән мөселманнар делегациясе белән идарә итүе турындагы вакыйгадан өзек:

Византия патшасына Пәйгамбәребезнең көрәштәше Һишам җитәкчелегендә мөселманнар делегациясе юнәлгән. Патша аларны кабул иткән, утырырга кушкан һәм күп кечкенә бүлемнәре булган сандыкны алып килергә кушкан. Аннары ул сандыкны ачып, аннан кара ефәккә төрелгән сурәт алган да, аны күрсәтеп: «Сез бу кешене беләсезме?» – дип сораган. Алар: «Белмибез», – дип җавап биргәннәр. Шунда патша: «Бу сезнең борын бабагыз Адәм», – дигән һәм яңадан шул ук ефәккә төреп, кире урынына салып куйган. Аннары ул икенче тапкыр сандыкны ачып, аннан кара ефәккә төрелгән сурәтне алган да: «Ә сез моны беләсезме?» - дип сораган. Сәхабәләр яңадан кире җавап биргәннәр. «Бу сезнең бабагыз Ибраһим», – дип җавап биргән патша. Өченче тапкыр ул кабат сурәт тартып чыгарган да: «Монда сурәтләнгән кешә сезгә танышмы?» - дип сораган. «Юк», - дигән җавапка ул: «Бу сезнең бабагыз Гыймран улы Муса», - дигән. Шул рәвешчә Мөхәммәд Пәйгамбәргә килеп җиткәнчә, ул барлык сурәтләрне дә сандыктан чыгарган һәм: “Сез бу кешене беләсезме?» - дип сораган. Сурәтне күргәч, алар кычкырып елап җибәргәннәр. Патша: «Сез ник елыйсыз соң?» - дип сораган. Алар: «Бу безнең Пәйгамбәребез бит», - дип җавап биргәннәр һәм: «Бу рәсемдә ул, әйтерсең, безнең арабызда кебек», - дип өстәгәннәр. Шуннан соң алар римлыларның дәүләт башлыгыннан аңа бу сурәтләрнең каян килгәнлеген сораганнар. Ул Адәм Пәйгамбәрнең Аллаһы Тәгаләдән үзенең нәселеннән булган бөтен илчеләрнең сурәтләрен күрсәтергә соравы хакында сөйләп биргән. Шул чакта Аллаһы Тәгалә аңа бөтен илчеләрнең дә яшел ефәккә төрелгән сурәтләрен җибәргән. Һәр җомгада Адәм аларны үзенең балаларына күрсәткән. Ул аларны сандыкта саклаган. Үләр алдыннан Адәм сандыкны үзенең улы Шиска тапшырган, ә ул, үз чиратында, аны үзенең улы Анушка биргән. Шул рәвешчә кулдан-кулга күчеп, сандык Зөлкарнайга килеп җиткән. Аннары ул безнең борынгы бабаларыбызга тапшырылган, һәм шул рәвешчә безгә килеп җиткән.

Бу турыда язарга мине кайбер «галимнәрнең” минем өемдә эленеп торган Сәйфулла казый фотосурәте тирәсендәге бәхәсләре мәҗбүр итте. Мин сөйгән Аллаһыны танып белүче суфиларның (гарифун) һәм әүлияләрнең фотосурәтләрен стенага да эләм, ә әгәр дә телим икән - алып куям, һәм бу рөхсәт ителә. Әгәр ярамый икән, ни өчен соң алайса исән һәм үлгән Согуд король һәм принцларның сурәтләрен стенага эләләр? Әмма шул ук вакытта Согуд Гарәбстанында бер генә һәйкәл дә күрмәссең. Һичьюгы шушы скульптура белән фотографиянең аермалылыгын әйтмимени соң? Яраткан кешеңнең йөзен һәрвакыт күрәсе килеп тора. Моның киресен әйтүче ялган сөйли. Әстәгъфируллаһ! Аллаһы безнең барыбызны да гафу итсен!

**Сәед ЧИРКАВИ.**
*(“Иман” газетасыннан)*

# Гаилә изгелеге

Аллаһы Тәгалә ялгызлыкны Үзенә генә хас кылып бөтен мәхлукларына парлык нигъмәтен бүләк итте. Бу турыда Коръәндә менә ничек әйтелә: *«һәм галәмәтләреннән: Ул үзегезгә бергә торыр өчен сезнең үзегездән хатыннар барлыкка китерде һәм Ул арагызда мәхәббәт вә мәрхәмәтлелек ясады. Хакыйкатьтә, фикерләп караган кавемгә монда галәмәтләр бар!»* (Рум, 21).

Ислам кешеләрне никахлы гаилә корып сөю-мәхәббәттә, тугрылык вә тигезлектә тормышны үткәрүгә чакыра. Никах фәкать ир-хатынлык мөнәсәбәтләре белән генә чикләнмичә, бәлки, ахирәттә җәннәттә лаек булу өчен дә хезмәт итәдер.

Никахның олы нигъмәт икәнлеге турында Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.) шулай дигән: *«Кеше гаилә корса, диненең яртысын мөкәммәл кылган була, калган яртысы мөкәммәл булуы өчен тәкъва булсын».*

Кеше ялгыз яши алмый, ул даими башкаларның әлфәт-мәхәббәтенә вә ярдәменә мохтаҗ. Шуның өчен ислам аларны гаилә коруга вә үзеннән соң балалар калдыруга этәрә.

Рәсүлуллаһ (с.) бу турыда болай дигән: *«Никах - минем сөннәтем, кем ки аннан баш тарта исә, ул минем өммәтемнән түгел».*

Башка бер хәдис-шәрифтә: *«Мәхәббәтле, бала табарлык хатыннарга өйләнегез, чөнки мин Кыямәт көнне өммәтемнең күплеге белән горурланырмын»,* – диелгән.

Никах кешенең динен, динаятьчелеген ныгытып куя, тормышына фәез-бәрәкәт алып килә. Менә ни өчен ул Аллаһының разыйлыгына ирешү юлы була да инде.

Гаилә башлыгы булган ир кеше даимән





*ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ*

# Бир, Ходаем, сабырлык!

**Кырык җиде яшендә, каты авырудан вафат булган газиз балама - Фәридә кызыма багышлыйм**

Бисмилла диеп башладым
Бу бәетнең башларын,
50 яшькә дә җитмәдең,
Гүргә керде башларың.

Өскә менсәм, тавы биек,
Түбән төшсәм — тамырлык,
Бу хәсрәттән ни хәл итим,
Бир, Ходаем, сабырлык.

Сулар сибеп гөл үстердем
Матур итеп савытта.
Син дә матур чәчәк идең
Үсеп килгән вакытта.

Бакчаларга чыккан идем
Дөрләп яна карама.
Мингалием, синдә калды
Балаларны карарга.

Тәмле диеп ашамагыз
Дарулы алмаларны.
Ни хәл генә итим инде
Калдырдың балаларны.

Кара бөдрә чәчләремне
Кирәк иде үрергә,
Бер минутка кайтыр идем
Балаларны күрергә.

Бакчадагы җиләкләрне
Үткәндә таптамагыз.
Хәзер инде үзе юк дип,
Кызымны ташламагыз

Акбүз атның ялкайларын
Үзем генә үрә алмыйм.
Бакыйлыкка күчтем инде,
Хәзер сезне күрә алмыйм.

Матур итеп кошлар сайрый,
Сызлап таңнар атканда.
Әнекәем, исеңә ал,
Намазлыкка басканда.

Безгә каршы су буенда
Тирән чишмә уйганнар.
Әрнү булдым инде сезгә,
Ни хәл итим, туганнар?!

**Җәүһәр БУЛАТОВА,**
**пенсионер, хезмәт ветераны.**
Мәчәләй авылы,
Похвистнево районы.




**- Җомга вәгазен сөйләгәндә бүлдереп, урыннан гына сорасалар, имам аңа җавап бирергә тиешме? Бу шәригать кануннары буенча рөхсәт ителәмени? Гомумән, кем дә булса имамны бүлдерә аламы? Әгәр шундый хәл килеп чыгып, сорау биргәннәр икән, имам үзен ничек тотарга хаклы? Җәмәгатькә болай кыланырга рөхсәт итмәскә тиештер бит ул?**

- Беренчедән, җомга вәгазен тыңларга килгән мөселманнарга имамны игътибар белән тыңлау зарур. Чөнки анда Аллаһының рәхмәте, Коръән, Кыямәт көне турында сүз бара, шулай ук үгет-нәсыйхәт бирелә, сабак алырлык мисаллар китерелә. *«Коръән укылса, аны тыңлагыз һәм эндәшмәгез. Шаять, сез мәрхәмәткә ирешерсез!»* – диелә изге Коръәндә («Әл-Әгъраф» сүрәсе, 204 нче аять). Коръән сүрәләренә аңлатма бирүче күпләр бу аятьтә сүз вәгазь турында бара дип белдерә. Шулай ук Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә дә вәгазь барышында сөйләшергә ярамавы хакында ачык итеп күрсәтмәләр бирелгән. Пәйгамбәрнең: *«Әгәр дә син җомга намазында имам вәгазь сөйләгәндә дустыңа: «Имамны тыңла», – дисең икән, бу – сафсата булыр»,* – дип әйткәне Әбү Һурайра тарафыннан да китерелә. Галинең «Имамга якын килгән кеше сафсата белән шөгыльләнер, тыңламыйча сөйләвен дәвам итсә, гөнаһ кылыр. Шунда берсе: «Дәшмәгез», – ди икән, ул да сафсата сатар. Димәк, аңа җомга намазының савабы юк. Пәйгамбәрнең шулай дигәнен ишеттем», – дип әйткәне дә риваять ителә. Шулай ук Ибн Габбас тарафыннан да Пәйгамбәрнең: *«Җомга көнендә имам вәгазе вакытында сөйләшеп утырган кеше китаплар төягән ишәк төсле (бернинди файда алмый дигәнне аңлата), ә берәү аңа: «Тыңла», – ди икән, аның да җомга намазы саналмый»*, – дигән сүзләре китерелә.

Гыйлем ияләре әйткән фикергә нәтиҗә ясап, болай әйтергә була: җомга вәгазе вакытында тыныч торырга, бик-бик мөһим ихтыяҗ булмаса, сөйләшмәскә, имамны игътибар белән тыңларга кирәк. Чөнки вәгазь вакытында бирелә булу һәм аны тыңлау өстәмә бүләкләнә. Әмма җыелган кешеләрнең берсе сүз катса яки сөннәткә каршы килгән гамәл кылса, имам аңа шелтә белдерә ала.

*(“Дин вә йола” газетасыннан)*